| | |
|---|---|
| Килешенде:<br>Татарстан Республикасы<br>Яр Чаллы шәһәре<br>Мәгариф идарәсе башлыгы<br>____________<br>Р.Н.Хузин | Раслыйм:<br>Муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе “21 нче гомуми урта белем бирү мәктәбе” директоры<br>____________<br>И.А.Хабибуллин |

“Мәктәп - белем учагы” III төбәкара нәфис сүз бәйгесе
нигезнамәсе

**Бәйгене үткәрү максаты һәм бурычлары**

Бәйге укучыларның татар әдәбияты белән кызыксынуын арттыру, татар телен тирәнтен үзләштерү, сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен булдыру, сәләтле балаларны барлау, милли тәрбия бирү максатыннан үткәрелә.

**Бәйгене оештыручылар**

Конференцияне оештыручылар:
- Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетының мәгариф идарәсе;
- Яр Чаллы шәһәре муниципаль бюджет учреждениесе “Мәгълүмати-методик үзәк»;
- Яр Чаллы шәһәренең муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе “21 нче гомуми урта белем бирү мәктәбе”.

**Бәйгедә катнашу тәртибе:**

Бәйгедә катнашучы укучылар татар шагыйрьләре, язучылары иҗатыннан 1 әсәр әзерли.

Гомуми белем бирү оешмаларының 1-11 нче сыйныф укучылары катнаша ала. Укучылар яшь үзенчәлекләренә карап түбәндәгечә бүленә:

- 1-2 сыйныф
- 3-4 сыйныф
- 5-6 сыйныф
- 7-8 сыйныф
- 9-11 сыйныф

Һәр номинациядә җиңүче, призер, лауреат, катнашучы дипломнары каралган.

**Бәйгенең юнәлешләре:**

«Нәфис сүз остасы» бәйгесе 3 юнәлештә үткәрелә:
1 юнәлеш- “Мәктәп, китап, уку, белем” темасына багышланган әсәрләр;
2 юнәлеш- “Укытучы, укучы” темасына караган әсәрләр
3 юнәлеш- “Яшь каләмче” (“Мәктәп - белем учагы” темасына укучыларның үзләренең иҗат җимешләре)

**Бәяләү критерийлары**

- Дикция, интонация, уку сәнгатьлелеге;
- Образга керү дәрәҗәсе;
- Сөйләүченең гәүдә торышы, хәрәкәте, мимикасы;
- Сөйләү темпының эчтәлеккә туры килүе.

Һәр пункт 5 балл системасында бәяләнә. Гомуми балл-20.

Искәрмә: жюри тарафыннан критерийлар тулыландырырга мөмкин.

**Оештыру комитеты һәм жюриның хокуклары һәм бурычлары:**

- Жюри критерийлар нигезендә гадел бәяли.
- Бәйге барышында жюри эшчәнлегенә комачаулау, укучылар алдында килешмәүне белдерүгә юл куелмый.
- Бәйгене оештыру, үткәрү, бәяләү критерийларына таләпләр буенча тәнкыйть һәм тәкъдим язма рәвештә оештыру комиссиясенә тапшырыла.
- Оештыру һәм үткәрү процессын камилләштерү максатыннан комиссия барлык фикерләрне өйрәнергә һәм киләчәктә гамәлгә ашырырга бурычлы.

**Бәйгене үткәрү урыны**

Бәйге Яр Чаллы шәһәренең муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе “21 нче гомуми урта белем бирү мәктәбе”ндә үткәрелә.

**Бәйгене үткәрү тәртибе**

Бәйге **ике этапта** үткәрелә.

**I этап** – читтән торып. Катнашучы **2023 нче елның 20 нче октябренә** кадәр катнашу өчен гариза (кушымта 1), видеоязманы (видеязмага ссылка), түләү квитанциясен dgauhar75@mail.ru электрон адресына җибәрелә (темага туры килмәгән, күрсәтелгән вакыттан соң килгән эшләр бәйгегә кабул ителми).

Бәйгедә катнашу өчен 150 сум күләмендә (һәр эш өчен) оештыру взносы түләргә кирәк. Квитанция копияләрен гариза-заявка,эшләр белән бергә **архивлаштырмыйча** җибәрү сорала. Оештыру взносы дипломнар, сертификатлар, оештыру эшләре өчен тотыла: *кушымта №2*

Оештыру комитеты тикшергәннән соң беренче этап нәтиҗәләре Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре “21 нче урта гомуми белем мәктәбе”нең официаль сайтына 25.10.2023 соң эленә (https://edu.tatar.ru/n_chelny/sch21chelny).

**II этап** - бәйгенең төп этабы. Уңышлы дип табылган эш чыгышлар 2023 нче елның 30 октябрендә Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәренең 21 нче урта гомуми белем мәктәбенә бәйгегә чакырыла. Укучы үзе сайлаган әсәре белән чыгыш әзерли. Чыгыш ясау вакыты – 5-7 минут

**Искәрмә:** 1 укучы 1 юнәлештә генә чыгыш ясый ала. 1 укучыда бер генә фәнни җитәкче булырга тиеш.

Элемтәгә керү өчен кәрәзле телефон: 89872389640 (МБ җитәкчесе Демухаметова Гәүһәр Фаяз кызы)

**Бәйгене йомгаклау һәм нәтиҗә ясау**

Катнашучыларның чыгышларын тыңлап бетергәннән соң, эксперт комиссиясе утырышы үткәрелә һәм җиңүчеләр турында карар чыгарыла. Нәтиҗә 2023 нче елның 30 октябрендә ясала.

Эксперт комиссиясенең карары протоколлаштырыла.

Бәйгедә җиңүчеләргә дипломнар, сертификатлар бирелә.

*Кушымта №1*

| АНКЕТА | |
|---|---|
| Башкарылачак әсәрнең авторы, исеме | |
| Юнәлеш | |
| Катнашучының фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (тулысынча) | |
| Сыйныф | |
| Оешма исеме (устав буенча), адресы,телефоны | |
| Җитәкченең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме | |
| Катнашучының телефоны электрон адресы | |

*Кушымта 2*

| | |
|---|---|
| Полное наименование организации | Муниципальное автономное общеобразовательное учреждение города Набережные Челны «Средняя общеобразовательная школа № 21» |
| Краткое наименование организации | МАОУ «СОШ № 21» |
| Юридический адрес, фактический адрес | РТ, г. Набережные Челны, ул. Железнодорожников д. 65 |
| ИНН/КПП | 1650083359/165001001 |
| Расчетный счет | 03234643927300001100 |
| л/с | ЛАВ30800070-СОШ21 |
| Наименование банка | ОТДЕЛЕНИЕ-НБ РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН БАНКА РОССИИ//УФК по Республики Татарстан г.Казань |
| Корреспондентский счет | 40102810445370000079 |
| БИК | 019205400 |